**Муниципальное автономное общеобразовательное учреждение**

**«Усть-Туркская средняя общеобразовательная школа» Бажуковский филиал**

| | |
|---|---|
| СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| Заместитель директора по УВР | Директор МАОУ «Усть-Туркская СОШ» |
| / Аитова Э.Р. | / Юсупова И.Ф. |
| «30» августа 2024 г. | Приказ №123 от «30» августа 2024 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**курса внеурочной деятельности**

**«Интересная грамматика»**

для обучающихся 3 го класса

**с. Бажуки, 2024г.**

**Аңлатма язуы**

Башлангыч гомуми белем бирүдә яңа федераль дәүләт стандартларының төп максаты һәм бурычы булып балаларда белем алырга кызыксыну һәм теләк уяту, мөстәкыйль уйларга, алган белемнәрен практикада куллана белергә өйрәтү тора. Яңа буын федераль дәүләт стандартларының принципиаль аермалыгы булып белем алуның күрсәткеченә, нәтиҗәсенә ориентлашу тора.

Балага белем һәм тәрбия уен аркылы аеруча кече яшьтә әйбәт бирелә.Уйнаган чакта бала күп нәрсәне таный, күнекмәләр ала. Шуны истә тотып мин, балалар белән татар телен ныгырак үзләштерү максатыннан, “Кызыклы грамматика” түгәрәге алып барырга дигән фикергә килдем. Уен баланың шул фән белән кызыксынуын көчәйтә, мөстәкыйльлеген , ихтыяр көчен, акыл эшчәнлеген, тапкырлыгын үстерә, аны милли бердәмлек рухында тәрбияли, билгеле бер максат куеп эшләргә өйрәтә.Яңа программалар балаларның ныклы белем, тотрыклы күнекмәләр алуын гына түгел, мөстәкыйль рәвештә танып-белү эшчәнлеге белән кызыксынуларын да уятуны һәм шуны кече яшьтән үк кешенең күнекмәсенә әйләндерә баруын күздә тота.

Борын заманнан ук балаларны ана теленә өйрәткәннәр, баланың телен шомартуга, сүзлек хәзинәсен арттыруга, сөйләгәндә һәм язганда, аннан оста файдалануга бик нык игътибар иткәннәр. Ана баласына “тел ачкычы” бирү өчен, бишек җыры җырлаган, сүзле уеннар оештырган; үсә төшкәч такмаклар, тизәйткечләр, санамышлар, табышмаклар өйрәткән, бәетләр әйткән, әкиятләр сөйләгән.
Бу түгәрәккә алынган уеннар , мавыктыргыч күнегүләр, табышмак, башваткыч, кызыклы әңгәмәләр, әкият һәм мәзәкләр укучыда ана теленә мәхәббәт тәрбияләр, телгә карата тирән кызыксыну уятыр дип өметләнәм.

Түгәрәк программасы 3 нче сыйныфта балаларга татар телен тирәнрәк өйрәнү өчен төзелгән. Әлеге программа 34 сәгатькә исәпләнгән. Ул атнага 1тапкыр үткәрелә . Програмада тәкъдим ителгән темалар укучылар өчен кызыклы, аларны иҗади эзләнергә, фикер йөртергә өйрәтә, мәктәп программасының дәвамы була ала.

***Түгәрәк программасының максаты:***

Кече яшьтәге мәктәп укучыларының татар теле фәне буенча белемнәрен киңәйтү, тирәнәйтү һәм ныгыту; укучыларны татар теленең кызыклы фән булуына төшендерү.

***Программаның бурычлары:***

**Дидактик:**

- татар теленә уку фәне буларак кызыксыну үстерү;
- татар теле грамматикасы буенча белем, күнекмәләр булдыру;
- укучыларның сүзлек запасларын үстерү;
- укучыларда татар теленә хөрмәт һәм ихтирам тәрбияләү, телнең чисталыгын, дөреслеген саклау, телне, халыкның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту;

**Тәрбияви:**

• китап белән эшли белү культурасы тәрбияләү;

•укучыларда фикерләү культурасы, кызыксыну формалаштыру һәм үстерү;

**Үстерелешле:**

- укучыларның фикер йөртүен һәм тапкырлыкларын үстерү;
- төрле сүзлекләр белән эшли белүләрен үстерү;
- балаларны текст, китап белән эш итү алымнарына өйрәтү;

**<u>Укыту программасына нигезләнеп үзләштерү нәтиҗәләре</u>**

**Шәхескә юнәлтелгән УУГ (универсаль уку гамәлләре)**

- үз эшчәнлегенең нәтиҗәләрен яхшыртуга ихтыяҗ формалаштыру;
- үз мөмкинлекләреңне бәяләү, тормыш тәҗрибәсен куллану;

- түгәрәктә үзенең белем һәм күнекмәләрен куллану;
- үз фикереңне әйтә белү;
- иҗади эшчәнлеккә омтылыш булдыру;

**Танып белү универсаль уку гамәлләре**

- үзенә кирәкле информацияне таба белү; анализлый һәм информацияне бәяли белү;
- логик фикерләү чылбырын төзү;
- тәкъдим ителгән план ярдәмендә предмет, күренешләрне сурәтләү;
- тәҗрибә куллану аша нәтиҗә чыгару;

**Регулятив (көйләгеч) универсаль уку гамәлләре**

- -белгәнне һәм белмәгәнне аера белү;
- -эшләнәчәк эшкә мөстәкыйль максат куя белү;
- -үз-үзеңне ихтыяр буенча көйләү;
- -бәяләү нәтиҗәсен шартлы символик формада чагылдыру;

**Коммуникатив универсаль уку гамәлләре**

- тыңлаучыларга аңлаешлы сөйләм төзү;
- күзаллау, фаразлау; логик фикер йөртү осталыгы; күршең белән
- хезмәттәшлек итү; фикерләү сәләтен үстерү, карарлар кабул итү һәм аны тормышка ашыру; үз фикереңне тулы, төгәл һәм ачык, аңлаешлы итеп әйтү, аны яклау;
- җитмәгән мәгълүматны башкалардан сорашып белү; иптәшеңнең үз-үзен тотышы белән идарә итү.

***Курсның программасы:***

- укучыларның татар телен өйрәнүгә карата иҗади активлыкларын арттыру;
- сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның киләсе үсешенә булышлык күрсәтү.
- түгәрәк турында кыскача мәгълүмат бирү;
- дәрестә алган грамматик, орфографик, пунктуация, сөйләм теле һәм язу күнекмәләрен ныгыту һәм үстерү;

- иҗат эше белән шөгыльләнү һәм материалларны төрле басмаларга тәкъдим итү;
- төрле темаларага проектлар эшләү;
- төрле бәйгеләрдә катнашу;
- еллык эшкә йомгак ясау.

**Көтелгән нәтиҗәләр:**

-матур итеп сөйләшә белү,

-дөрес итеп язу

-белемнәрен практикада кулану

-төрле конкурсларда катнашу.

**Тематик план**

| № | Бүлекләр | Сәгатьләр санны | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Барысы | Теория | Практика |
| 1 | Тыңларга, ишетергә. Дөрес әйтергә өйрәтү күнегүләре | 1 | | 1 |
| 2 | Эзләнергә, уйларга һәм исбат | 1 | | 1 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | итәргә өйрәтү күнегүләре | | | |
| 3 | Дидактик уеннар | 2 | | 2 |
| 4 | Авазлар һәм хәрефләр | 4 | 1 | 3 |
| 5 | Дөрес язу | 4 | 1 | 3 |
| 6 | Предметларны төркемләү. | 2 | 1 | 1 |
| 7 | Сүз төзелеше | 2 | 1 | 1 |
| 8 | Сүз төркемнәре | 2 | 1 | 1 |
| 9 | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. | 2 | 1 | 1 |
| 10 | Сүз уеннары һәм башваткычлар | 2 | | 2 |
| 11 | Табышмаклар. Аларның җавабын табу юлларын өйрәтү. | 1 | | 1 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 12 | Тест биремнәре чишү. | 5 | | 5 |
| 13 | Язма эшләр | 6 | | 6 |
| Барысы | | 34 | 6 | 28 |

**“Кызыклы грамматика” түгәрәгенең программа эчтәлеге**

| №п\п | Үткәрү вакыты | Бүлекләр | Тема | Сәгатьләр саны | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Теория | Практика |
| 1 | 5.09. | Тыңларга, ишетергә. Дөрес әйтергә өйрәтү күнегүләре | Кереш.Программа белән таныштыру.Фонетик уеннар | | 1 |
| 2 | 12.09. | Эзләнергә,уйларга һәм исбат итәргә өйрәтү күнегүләре | Табышмаклар | | 1 |
| 3-4 | 19.09.<br>25.09. | Дидактик уеннар | “Кем баскычка тизрәк менә” уены | | 1 |
| | | | “Кем күбрәк белә” уены | | 1 |
| 5-8 | 3.10.<br>10.10. | Авазлар һәм хәрефләр | Авазлар һәм хәрефләр | 1 | |
| | | | Уеннар “Икеләтелгән тартыклар”, “Хәтердә калдырып буламы?”<br>“Бер сүздәге авазлардан ничә сүз ясап була” | | 1<br>1<br>1 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 9-12 | 17.10.<br>24.10.<br>7.11.<br>14.11 | Дөрес язу | Кайбер графика мәсьәләләре | 1 | |
| | | | Сүзгә кушымчалар ялгау<br>Төшеп калдырылган сүзләр өстәү<br>Җөмләләр уйлап язу | | 1<br>1<br>1 |
| 13-14 | 21.11.<br>28.11. | Предметларны төркемләү. | Предметларны төркемләү.<br>“Тартып алышлы”, | 1 | |
| | | | Уеннар: “Хайваннар”, Үсемлекләр”,<br>“Кошлар” | | 1 |
| 15-16 | 5.12.<br>12.12. | Сүз төзелеше | Әкият язу. “Булган ди бер тамыр” | 1 | |
| | | | Уен. “Тамырдаш сүзләр лотосы” | | 1 |
| 17-18 | 19.12.<br>26.12. | Сүз төркемнәре | Сүз төркемнәрен кабатлау | 1 | |
| | | | Уеннар “ Уннан артык исем”, “Аңлатып кара әле”, “Тематик лото” | | 1 |
| 19-20 | 9.01. | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. | Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. | 1 | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 16.01. | | | | |
| | | | Уеннар : “Чылбырлы”. “Кайсы сүз иярә, кайсы сүз ияртә”. “Хатасы нәрсәдә- тап һәм аңлат” | | 1 |
| 21-22 | 23.01.<br>30.01. | Сүз уеннары һәм башваткычлар | Сүз уеннары<br>Башваткычлар чишү | | 1<br>1 |
| 23 | 6.02. | Шарадалар. Аларның җавабын табу юлларын өйрәтү. | Шарадалар илендә | | 1 |
| 24-28 | 13.02<br>20.02.<br>27.02.<br>6.03.<br>13.03. | Тест биремнәре чишү. | “Хәрефләр” темасы буенча тест<br>“Авазлар” темасы буенча тест<br>“Лексика” темасы буенча тест<br>“Сүз төзелеше” темасы буенча тест<br>“Исем” темасы буенча тест | | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 29-33 | 20.03.<br>3.04.<br>10.04.<br>17.04.<br>24.04. | Язма  эшләр | Мөстәкыйль эш<br>Рәсем буенча хикәя язу<br>Хәтер диктанты<br>“Безнең гаилә”<br>“Минем дустым” | | 1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| 34 | 8.05 | Нәтиҗә | Кабатлау. Эшкә йомгак ясау | | 1 |

**Балада түбәндәге белем һәм күнекмәләр формалашырга тиеш:**

-Балаларның фонематик ишетүе, тел байлыгы үсү, сүз сизгерлеге, акылы, логик фикерләве, фикерен дәлилләп аңлата белүе. игътибары, зиһене

Кулланылган әдәбият:С.Г.Вагыйзов “Кызыклы грамматика”, “Мәгариф” 2002, Г.Ясәбиева “Татар теле дәресләрендә вак әсәрләрне куллану” 2004 “Яр Чаллы пед.көллияте.”, “Энҗе чәчтем,энҗе җыям” ”Мәгариф”2002, Р.Ә Абдуллина, М.Х.Ханнанова “Татар теленнән тестлар” “Гыйлем” 2012